# КАРАР

**05 декабрь, 2024 ел** **№2**

**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Сәрдәүч авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 05 декабрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Сәрдәүч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Сәрдәүч авылында җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү; чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);
- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сәрдәүч авылының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, юл челтәрен карап тоту буенча башка эш төрләре) (Сәрдәүч авылы урамнарында юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, суүткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү; юлларны карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:
2023 елның 05 декабренә торак пунктта яшәүче гражданнарның гомуми саны – 27 кеше.

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 25 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 22 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 22 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Вильмон поселогында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Сәрдәүч авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Сәрдәүч авылында җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү; чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Сәрдәүч авылының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас

частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, юл челтәрен карап тоту буенча башка эш төрләре) (Сәрдәүч авылы урамнарында юлларга вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, суүткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү; юлларны карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Оштырма-Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.В. Тимофеев